# Татар орнаменты

Бергәләп бизибез




Сәлам, яшь рәссам! Вакытыңны кызыклы һәм файдалы уздырырга телисеңме? Безнең буягыч китап сиңа татар орнаменты турында сөйләр.

Орнаментлар бик борынгы заманнарда, язудан алдарак барлыкка килгән. Борынгы кешеләр дөнья төзелешен үзләренчә күргән һәм ясаган. Аларның төрле билге-символлардан торган рәсемнәренә мәгънә салынган. Димәк, орнаментлар – мәгълүмати портал, дия алабыз. Һәр орнамент рәсемендә шифр яшерелгән – сиңа шул серләрне ачарбыз.



Здравствуй, юный художник! Предлагаем тебе с пользой провести время. В этой книге-раскраске ты познакомишься с татарским орнаментом. Он появился очень давно, раньше, чем письменность. Первобытные люди рисовали свои представления о том, как устроен наш мир. Это были рисунки в виде знаков-символов, в которых был заложен смысл. Можно сказать, что орнамент — это информационный портал. Сегодня мы расскажем о том, что зашифровано нашими предками под каждым рисунком орнамента.


геометрик орнамент



чәчәкле-үсемлекле орнамент




зооморф орнамент



Орнамент — ул элементларның – орнамент мотивларының кабатлануыннан яки чиратлашуыннан торган бизәк. Татар бизәкләре өч төрле була: геометрик, чәчәкле-үсемлекле һәм зооморф.


геометрический орнамент




цветочный орнамент




зооморфный орнамент



Орнамент — это узор, который состоит из повтора или чередования элементов – мотивов орнамента. Татарские узоры – бизэк бывают трех видов: геометрические, цветочно-растительные и зооморфные.



Геометрик орнаментлар (түгәрәк, квадрат, өчпочмак, ромб) бик борынгы заманнарда барлыкка килгән. Галимнәр аларны безнең эрага кадәр 10-15 мең еллар элек булган дип саный. Зигзаглар, штрихлар, сызыклар балчык савытларны, агачтан һәм таштан ясалган әйберләрне бизәү өчен кулланылган. Борынгы кешенең дөнья турында үз күзаллавы булган. Түгәрәк – ул кояш, тулган ай, квадрат – җир яки теләсә кайсы тирәлек, өчпочмак – таулар, тәгәрмәч рәвешле әйләнә – хәрәкәт, спираль – ут һәм кояш билгесе.



Геометрические орнаменты (круг, квадрат, треугольник, ромб) появились в глубокой древности. Ученые считают, что возникли они за 15-10 тысяч лет до нашей эры. Зигзаги, штрихи, полоски применялись для украшения посуды из глины, предметов из дерева, камня. Древний человек имел свое представление о мире. Круг – это солнце, полная луна, квадрат – земля или любое пространство, треугольник – горы, круг в виде колеса – движение, спираль – знак огня и солнца.




Орнаментның тагын бер төре – чәчәкле-үсемлекле. Осталар үз эшләнмәләрендә табигатьтә булган үсемлекләрне, төрле чәчәкләрне – даланыкын (лалә, канәфер, күгәрчен күзе, мәк), кырныкын (кыңгырау, гөлҗимеш чәчәге, ромашка), бакчаныкын (георгин, хризантема, роза, астра) тасвирлаган.




Другой вид орнамента – это цветочно-растительный. Мастера на своих изделиях изображали растения, различные цветы: степные (тюльпаны, гвоздики, незабудки, маки), луговые (колокольчики, цветы шиповника, ромашки), садовые (георгины, хризантемы, розы, астры).



Татар осталары еш һәм яратып ясый торган бизәк – лалә. Лалә – мәхәббәт һәм табигатьнең язгы уяну символы. Роза чәчәге – матурлык һәм затлылык символы, ул күңел чисталыгын, яхшылык һәм мәрхәмәтне күрсәтә.



Самый часто изображаемый и почитаемый узор у татарских мастеров – это тюльпан – лэлэ – символ любви и весеннего возрождения природы. Цветок розы символизирует красоту и благородство, указывает на чистоту души, добро и милосердие.




Үсемлекле татар орнаментының үзәген буыннар һәм аның дәвамы, мәңгелек тормыш, дөнья тәртибе символы булган гомер агачы тәшкил итә.




Центральным мотивом татарского растительного орнамента является древо жизни, символизирующее род и его продолжение, вечность жизни, миропорядок.




Казан татарларында гомер агачы тамырлардан, кәүсәдән, сабаклардан, үсентеләрдән, бөреләрдән, чәчәкләрдән һәм җимешләрдән тора; еш кына күчәр тирәли симметрия белән ике кошчык ясала. Чәчәк гөлләмәсе муллыкны, гаилә корган ир-ат һәм хатын-кыз башлангычын символлаштыра.





У казанских татар древо жизни состоит из корней, ствола, стеблей, ростков, бутонов; распустившихся цветов и плодов, часто изображается с двумя птичками по оси симметрии. Цветочный букет символизирует благополучие, единение мужского и женского начал, воплощенных в семье.






Гомумиләштерелгән һәм схематик бирелгән хайван сурәтләре (зооморф орнамент) кызыклы. Еш кына ыру яки кабилә билгесе буларак ясалган, орнаментта хайваннарга хас сыйфатлар бирелгән. Мәсәлән, ике башлы һәм җәелгән канатлы кош ике ыруның берләшүе, эшләренең уңышлы баруы символы, шулай ук, хакимият символы булган.







Большой интерес представляют изображения животных (зооморфный орнамент), которые передаются обобщенно и схематически. Часто их изображали в качестве знака рода или племени, в орнаменте передавали характерные черты животных. Например, птица с двумя головами и раскрытыми крыльями была символом объединения двух родов, их процветания и успехов в делах, а также символом власти.




Кошлар образлары белән байтак ышанулар, әкиятләр һәм риваятьләр бар. Бик күп предметларда кулланылган үрдәк образы Тәңре кушуы буенча дәрья төбеннән алынган бер чеметем туфрактан җир яралу турындагы татар риваятен сурәтли.



С образами птиц связаны многие поверья, сказки и легенды. Образ уточки на многих предметах иллюстрирует татарскую легенду о создании Земли из комочка тверди, взятой, по велению Всевышнего (Тенгри), со дна Мирового океана.



Орнаментны куллану һәм аның символикасы сурәтнең нинди предметка төшерелүенә бәйле. Мәсәлән, тукучылыкта, агачны бизәкләүдә геометрик мотивлар өстенлек итсә, чигүдә, келәмнәрдә композициясе математик төгәллек белән урнаштырылган чәчәкле бизәкләр кулланыла.



Использование и символика орнамента зависят от того, на какой предмет наносится изображение. Например, в ткачестве, резьбе по дереву преобладают геометрические мотивы, а в вышивках, на коврах – цветочные, расположенные в композиции с математической точностью.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘ ИННОВАЦИЯЛӘР
ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ САКЛАУ РЕСУРС ҮЗӘГЕ

# Татар орнаменты

Балалар өчен рәсемле буяу китабы

Татарстан Республикасының «Татар халкының
милли үзенчәлеген саклау (2020–2024 еллар)»
дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында
нәшер ителә.

**Буягыч китапта**
**Валеев Ф. Х. Татарский народный орнамент / Науч. и отв. ред. доктор искусствовед. Г. Ф. Валеева-Сулейманова. – Казань, 2002. – 295 с. басмасыннан алынган орнамент үрнәкләре кулланылды**

Рәссам – **Мусабирова Р. М.**

Идея авторы – **Мифтахова А. Р.**, «Татарстанның мәдәният ресурс үзәге» ДБУ директоры.

Фәнни консультант – **Вәлиева-Сөләйманова Г. Ф.**, сәнгать фәннәре докторы,
ТР ФА Ш. Мәрҗани ис. тарих институтының баш фәнни хезмәткәре.

Текст авторлары – **Латыйпова Г. М., Камалова Д. Х.**

Татар теленә тәрҗемә итүче – **Мөхәммәтова Р. Р.**

Казан 2022

МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ГБУ «РЕСУРСНЫЙ ЦЕНТР ВНЕДРЕНИЯ ИННОВАЦИЙ И СОХРАНЕНИЯ ТРАДИЦИЙ
В СФЕРЕ КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

# Татарский орнамент

Книга-раскраска для детей

Печатается в рамках реализации государственной программы
Республики Татарстан «Сохранение национальной идентичности
татарского народа (2020–2024 годы)».

**В раскраске использованы образцы орнаментов из книги
Валеев Ф. Х. Татарский народный орнамент / Науч. и отв. ред. доктор
искусствовед. Г. Ф. Валеева-Сулейманова. – Казань, 2002. – 295 с.**

Художник — **Мусабирова Р. М.**

Автор идеи — **Мифтахова А. Р.**, директор ГБУ «Таткультресурсцентр».

Научный консультант — **Валеева-Сулейманова Г. Ф.**, доктор искусствоведения,
главный научный сотрудник Института истории им. Ш. Марджани АН РТ.

Авторы текста — **Латыпова Г. М., Камалова Д. Х.**

Корректор русского текста — **Мухаметшина Л. Т.**

Перевод на татарский язык — **Мухаметова Р. Р.**

Подписано в печать 14.12.2022.
Тираж 2000 экз. Заказ №
Отпечатано в...........

Казань 2022

